Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3; 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш), 2023, № 27 (I өлеш); 2026, № 2 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) дүртенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт флагы дәүләт (муниципаль) милкендәге спорт объектларына, милек рәвешләренә карамастан, гомуми белем бирү оешмалары биналарына, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек алып баручы дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә (яшьләр сәясәте учреждениеләренә) даими элеп куела йә даими рәвештә аларның территорияләрендә урнаштырыла.»;

б) түбәндәге эчтәлекле бишенче өлеш өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт флагы, милек рәвешләренә карамастан, гомуми белем бирү оешмалары, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек алып баручы дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр (яшьләр сәясәте учреждениеләре) тарафыннан уздырыла торган массакүләм чаралар вакытында, шулай ук рәсми физик культура чаралары һәм рәсми спорт чаралары үткәргән вакытта күтәрелә (куела).».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Россия Федерациясе Дәүләт флагы турында» Федераль конституциячел законның 4 һәм 6 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2026 елның 26 июнендәге 2-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон (алга таба – 2-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон) белән биналарына Россия Федерациясе Дәүләт флагы даими рәвештә эленеп торырга (куелырга) мөмкин оешмалар исемлеге киңәйтелде.

Әлеге статьяның гамәлдәге редакциясендә (2-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон үз көченә кергәнче) әлеге бурыч, милек рәвешләренә карамастан, гомуми белем бирү оешмаларына, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру буенча эшчәнлек алып баручы дәүләт учреждениеләренә һәм муниципаль учреждениеләргә (яшьләр сәясәте учреждениеләренә) кагыла иде.

2-ФКЗ номерлы Федераль конституциячел закон нигезендә Россия Федерациясе Дәүләт флагы шулай ук дәүләт (муниципаль) милкендәге спорт объектларында даими эленеп торырга, шулай ук рәсми физик культура чаралары һәм рәсми спорт чаралары үткәргән вакытта күтәрелергә (куелырга) тиеш.

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты белән гамәлдәге республика Законына Россия Федерациясе Дәүләт флагын дәүләт (муниципаль) милкендәге спорт объектларында, шул исәптән рәсми физик культура чаралары һәм рәсми спорт чаралары үткәргән вакытта, даими рәвештә элеп куюга кагылышлы шундый ук үзгәрешләр кертелә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары актларының үз көчен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.